ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
АЛЕКСЕЕВСК
ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 6 июне 12

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге Башкарма комитетының «Күчемсез милек объектына адрес бирү (үзгәртү, аныклау, гамәлдән чыгару) буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты» дип аталган 2015 елның 26 октябреннән 21 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Гамәлдәге законнарга, шул исәптән РФ Шәһәр төзелеше кодексы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законга, «Адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару Кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы РФ Хөкүмәте карарына туры китерү максатында

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге

Башкарма комитетының «Күчемсез милек объектына адрес бирү (үзгәртү, аныклау, гамәлдән чыгару) буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты» дип аталган 2015 елның 26 октябреннән 21 номерлы карарына түбәндәге эчтәлектәге үзгәрешләр кертергә:

1.5 пунктының 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«капиталь төзелеш объекты – капиталь булмаган биналар, корылмалар һәм тиешенчә яхшыртылмаганган (җирне каты өслек белән каплаган һ.б.) җир кишәрлекләреннән тыш, төзелеш эшләре тәмамланмаган бина, корылма (алга таба – тәмамланмаган төзелеш объектлары); »;

2 бүлектә «Хезмәт күрсәтү стандарты»

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының эчтәлегендәге 2.5 юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« 1) Гариза (кушымта № 3);

2) Шәхесне раслаучы документлар;

3) Вәкил вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр мөрәҗәгать итүче исеменнән вәкил эшли икән);

4) объект (объектларга) адресация документларын хокукый дәлилли торган һәм (яисә) хокукын билгели торган документлар;

5) бер һәм аннан да күбрәк адресация объекты барлыкка килгәндә үзгәртеп корылган күчемсез милек объектларының кадастр паспорты (күчемсез милек объектларыннан бер һәм аннан да күбрәк яңа адресация объектлары барлыкка килгән очракта);

6) адресация объекты төзелешенә (төзелеп килүче адресация объектларына адресын биргәндә) рөхсәт бирү һәм (яки) объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү;

7) адресация объектының тиешле территориянең кадастр планында яки кадастр картасында урнашу схемасы (җир кишәрлегенә адрес бирелгән очракта);

8) адресация объектының кадастр паспорты (кадастр исәбенә куелган адресация объектына адрес бирелгән очракта);

9) җирле үзидарә органының торак бинаны торак булмаган бинага яки торак булмаган бинаны торак бинага күчерү турындагы карары (торак бинаны торак булмаган бинага яки торак булмаган бинаны торак бинага күчерү нәтиҗәсендә әлеге бинага адрес бирү, адресын үзгәртү һәм гамәлдән чыгару очрагында);

10) бер һәм аннан да күбрәк яңа адресация объектларын барлыкка китерүче бинаны үзгәртеп корганда һәм (яки) үзгәртеп планлаштырганда төзелгән кабул итү комиссиясе акты (бер һәм аннан да күбрәк яңа адресация объектлары барлыкка килгәндә күчемсез милек объектларын (биналарны) үзгәртеп корган очракта);

11) исәптән төшерелгән күчемсез милек объекты турында кадастр өземтәсе (адресация объектының барлыгы гамәлдән чыгарылу сәбәпле аның адресы юкка чыгарылган очракта);

12) дәүләти күчемсез милек кадастрында адресация объекты буенча соралган белешмәләрнең булмавы турында хәбәрнамә (объектка яңа адрес бирү белән бәйле рәвештә адресация объектының адресын гамәлдән чыгарган очракта).

Гариза ике нөсхәдә бирелә, документлар – бер нөсхәдә»;

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының эчтәлегендәге 2.6 юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5 пунктында күрсәтелгән исемлекнең 4 дән 12 гә кадәрге документлары ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында бирелә»;

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының эчтәлегендәге 2.9 юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигез каралмаган.

Баш тарту өчен нигез булып тора:

1) гариза хокуксыз зат тарафыннан бирелү;

2) мөрәҗәгать итүче тарафыннан документлар тулы күләмдә тапшырылмаган, яисә тапшырылган гаризада һәм (яки) документларда тулы булмаган һәм (яисә) дөрес булмаган мәгълүмат булу;

3) ведомствоара соратып алуга биргән җавапта адресация объектына адрес бирү яки адресны гамәлдән чыгару турындагы документ һәм (яки) мәгълүмат булмавы һәм тиешле документ гариза бирүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) тарафыннан үз теләге буенча тапшырылмаган очракта;

4) мөрәҗәгать итүченең вәкиле бирергә тиешле адресация объектына адрес бирү
яки аның адресын гамәлдән чыгару турындагы документлар Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртипне бозып бирелгән очракта;
5) адресаця объектына адрес бирү яки аны гамәлдән чыгару өчен сәбәпләр һәм
шартлар булмау;
6) объект әлеге Регламентның 1.5 пунктында күрсәтелгән күчемсез милек объектлары исемлегенә керми»;

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының эчтәлегендәге 2.14 юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гариза кәгазьдә Башкарма комитетка тапшырыла. Муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган бинага керү инвалидлар өчен Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә җайлаштырылган. Әлеге урын гаризаны рәсмиләштерү өчен өстәл, урындыклар гаризаны тутыру үрнәкләре һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге булган мәгълүмати стендлар белән җиһазландырыла»;

3.4.1 пунктын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Башкарма комитет белгече ведомствоара хезмәттәшлек тәртибе нигезендә Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны (аларның күчермәләрен, аларда булган мәгълүматларны) алар карамагында булган дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынган оешмалардан сорый.

Әгәр документлар дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы яисә дәүләт органнары яисә җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмалар карамагында булмаса, мөрәҗәгать итүчеләр (мөрәҗәгать итүче вәкилләре) гариза биргәндә аңа Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәргә хокуклы,.

Регламентның 2.5. пунктында күрсәтелгән, вәкаләтле органга электрон документлар рәвешендә тапшырыла торган, документлар мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүче вәкиле) тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза кулланып таныклана.

Процедураның нәтиҗәсе: хакимият органнарына җибәрелгән сортып алулар, гаризалар.»;

5.1 пунктның 3 пунктчасында «каралмаган документларны» сүзләрен «документлар яки мәгълүмат яисә гамәлләр башкару, тәкъдим итү яки гамәлгә ашыру каралмаган» сүзләренә алмаштырырга;

5.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 8 һәм 9 пунктчалар өстәргә:

«8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу;

9) әгәр туктату нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса, Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору.»;

5.7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.7 шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча Башкарма комитет җитәкчесе (авыл җирлеге башлыгы) түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка

чыгару, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән түләнмәгән акчаларны кире кайтару рәвешендә дә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарталар.

Шикаять тиешле дәрәҗәдә канәгатьләндерелергә тиешле дип танылган очракта,

дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенәләр һәм муниципаль хезмәт алу максатларында мөрәҗәгать итүчегә алга таба башкарырга тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять тиешле дәрәҗәдә канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга карата шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язма рәвештә һәм мөрәҗәгать итүченең теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталындагы җирлек сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге башкарма комитеты бинасында махсус мәгълүмат стендында урнаштырып халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Алексеевск шәһәр җирлеге**
**башкарма комитеты**
**җитәкчесе** **И.К. Свистунов**